**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 5 апрелендәге ПУ-203 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 6 июлендәге ПУ-429 номерлы, 2011 елның 7 февралендәге ПУ-47 номерлы, 2012 елның 14 августындагы ПУ-652 номерлы, 2013 елның 25 сентябрендәге ПУ-930 номерлы, 2014 елның 25 гыйнварындагы ПУ-45 номерлы, 2015 елның 7 февралендәге ПУ-104 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-23 номерлы, 2016 елның 21 мартындагы ПУ-267 номерлы, 2017 елның 20 гыйнварындагы ПУ-38 номерлы, 2017 елның 10 июнендәге ПУ-496 номерлы, 2017 елның 26 октябрендәге ПУ-975 номерлы һәм 2019 елның 6 маендагы ПУ-262 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.Ә. Абдуллинны, Д.Г. Калинкинны, С.А. Крайновны, О.М. Краснованы, С.В. Павловны, А.В. Прокофьевны, К.Г. Садриевны, Р.Х. Сөләймановны, А.Ш. Хөсәеновны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Гаффаров Рөстәм Гыйльфан улын – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Заһиров Айдар Рафаил улын – Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Миңнебаев Марат Фәйзрахман улын – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасарын;

Розенталь Андрей Николаевичны – Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Сәлахов Фәрит Шәүкәт улын – «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Тыгин Александр Васильевичны – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктур үсеш буенча комитеты рәисен (килешү буенча);

Хәбибуллин Роберт Наил улын – «Татэнергосбыт» акционер җәмгыяте директорының биллинг һәм физик затларга электр энергиясе сату буенча урынбасарын (килешү буенча);

Шәйдуллин Ирек Имам улын – Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасының баш дәүләт торак инспекторы урынбасарын;

в) Комиссия әгъзаларының вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

М.М. Әхмәтовның – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының реформалаштыру һәм объектларны модернизацияләү бүлеге башлыгы, Комиссия секретаре»;

Ә.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)»;

Д.С. Романовның – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының иҗтимагый контроль комиссиясе әгъзасы, «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә җәмәгать контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы башкарма директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ ГОМУМИ БҮЛЕК — АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 30 ноябрь
№ ПУ-786